ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, , 423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы,
37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
N 5

КАРАР
15.03.2024 ел

2023 елның 17 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 санлы, 2023 елның 17 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 1/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Уставының 22 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 25 мартында 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Бәйрәкәтамак торак пункты, Яңа урам, 36 йорт адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасы янында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында 2023 елның 17 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 санлы, 2023 елның 17 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 1/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез эшләнәсе эшләрне түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 17 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 санлы, 2023 елның 17 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 1/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертүгә сез ризамы:

«1)Бәйрәкәтамак торак пунктында традицион күмү урыннарын төзекләндерү ремонтлау, коймалау (зират территориясен койма белән уратып алу, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Бәйрәкәтамак торак пунктында торак пункт территориясен төзекләндерү (халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау (балалар мәйданчыгы өчен МАФ сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) Байрәкәтамак торак пунктында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирлек эчендәге юлларны карап тоту, кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)».

«РИЗА» «КАРШЫ».

3.Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (реер//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар аның игълан ителү көненнән үз көченә керә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы ______________ З.М.Әһлиева
(имза)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Для документов
СОВЕТ БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН